ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2025 Казан ш. № 565-144/кс-2025

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Югары Ослан муниципаль районының «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2026 елга агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү һәм җитештерү программасын раслау турында» 27.08.2025 ел, №137-11/кс-2025 карарына 1 нче кушымтага үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 20 ноябрендәге 1834 номерлы карарын кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 15.12.2025 ел, №32-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Югары Ослан муниципаль районының «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2026 елга агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү һәм җитештерү программасын раслау турында» 27.08.2025 ел, №137-11/кс-2025 карарына 1 нче кушымтага үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә (кушымтада) бирергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинова

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 27.08.2025 ел, № 137-11/кс-2025 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2025 № 565-144/кс-2025 карары редакциясендә) 1 нче кушымта

Агып җыела торган суларны агызуны гамәлгә ашыручы «РСК» ҖЧҖ өчен
2026 елга агынты суларны транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Агынты суларны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр |
| | Югары Ослан муниципаль районы | | |
| 1 | «РСК» ҖЧҖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 2,25 | 2,70 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге